| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.01.2020 г. Казань № под-149/20

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2019 елның 8 октябрендәге под-1418/19 номерлы боерыгы белән расланган Балигъ булмаган баланы тулысынча эшкә сәләтсез дип игълан итү (эмансипацияләү) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең типлаштырылган административ регламентына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына хезмәт эшчәнлеге турындагы мәгълүматларны электрон рәвештә формалаштыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ номерлы федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Балигъ булмаган баланы тулысынча эшкә сәләтсез дип игълан итү (эмансипацияләү) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең типлаштырылган административ регламентын раслау турында» 2019 елның 8 октябрендәге под-1418/19 номерлы боерыгы белән расланган Балигъ булмаган баланы тулысынча эшкә сәләтсез дип игълан итү (эмансипацияләү) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең типлаштырылган административ регламентының 2 нче бүлегенә үзгәреш кертеп, 2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының җиденче азацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«балигъ булмаганнарның хезмәт эшчәнлеген раслаучы документлар (хезмәт килешүе (контракт) яки хезмәт кенәгәсе күчермәләре), яисә тиешле рәвештә расланган хезмәт эшчәнлеге турында кәгазьдә яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә мәгълүматлар;».

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлегенә (В.О.Васильева) боерыкны

имзалаганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.М.Әсәдуллинага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер министры урынбасары – министр Р.Т.Борһанов